ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.06.2024 г. Казань № 35-6/тп-2024

Тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә хисаплап, «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен 2022 елга түләү билгеләү турында

Татарстан Республикасы Арбитраж судының 29.05.2023 №А65-2649/2023 карарын, Унберенче арбитраж апелляция судының 30.08.2023 №11ап-12309/2023 карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 19.06.2024 №13-пр беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитеты карар бирә:

1. Тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә хисаплап, «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен 2022 елга әлеге карар кушымтасы нигезендә түләү билгеләргә.

2. «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә әлеге карар белән билгеләнгән тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен түләү акчалары хисабына төзелгән җылылык челтәрләрен «Химград» технополисы югары технологияләр өлкәсендә инновацион индустриаль парк – Технопарк» акционерлык җәмгыятенә тоташтыру турында шартнамә үтәлгәннән соң 30 календарь көн эчендә тапшыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. «Химград» технополисы югары технологияләр өлкәсендә инновацион индустриаль парк – Технопарк» акционерлык җәмгыятенә алынган мөлкәтне закон нигезендә теркәүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Д.А. Сапожников

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.06.2024 № 35-6/тп-2024
карарына кушымта

Тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек бирәмлегенә
хисаплап, «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән
җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру
(технологик ялгау) өчен 2022 елга түләү

мең сум/Гкал/сәг (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча)

| т/с | Атамасы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Гаризачыларның объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 9,842 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан гаризачыларның (П2.1) объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләре төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) гайре), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өслегеннән) салу | |
| 2.1.1 | 250 мм кадәр | - |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал итеп салу | |
| 2.2.1.1 | 250 мм кадәр | - |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | канал итмичә салу | |
| 2.2.2.1 | 250 мм кадәр | 2 114,61 |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан гаризачыларның объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзү (үзгәртеп кору) чыгымнары (П2.2) | - |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге